**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10.11.2023** **№ 1733**

**2024 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы карарының 3 пункты нигезендә, шулай ук белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне гамәлгә ашырганда автомобиль транспортыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга кушымта китерелгән түбәндәгеләрне расларга:
2024 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын (1 нче кушымта);
балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне (2 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль берәмлеге Финанс-бюджет палатасы» МКУнә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге карарның 1 пунктында расланган бәясе нормативлары нигезендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин

«Биектау муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге башкарма
комитеты җитәкчесенең
2023 елның 10 ноябре 1733 номерлы
карары белән расланды

2024 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасының моделе атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасының бер километр узуына ставка, елга сум |
| КАВЗ | 644807 | 23,31 |
| ПАЗ | 645065 | 23,47 |
| ГАЗ «Газель» | 624397 | 14,55 |
| УАЗ | 623944 | 13,18 |
| FIAT | 627292 | 10,99 |
| Peugeot Boxer | 632442 | 10,56 |
| Ford Transit | 632699 | 15,19 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 647022 | 20,69 |

«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 10 ноябре 1733нче номерлы карары белән расланды

2024 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында

нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең, автотранспорт чаралары санының һәм хисап чорына автотранспорт чараларының фактта йөрүенең нормативы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе нормативлары ел саен «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөреше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының факттагы йөреше буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m моделе автотранспорт чараларының фактта йөреше, километр;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясенең ставкасы бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына ставкасы, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.